РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2024г. г. Альметьевск № 322

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 36 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 114 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 143 номерлы, 2023 елның 06 декабрендәге 266 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составы» 2 нче кушымтада түбәндәге карарга:

- комиссия әгъзасы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Афлятунова Роза Егоровна - Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе;»;

- комиссия составына кертергә: «Коронова Светлана Васильевнаны - Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге баш белгече (килешү буенча);»;

- комиссия составыннан Ә.Б.Ханнанованы чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Туманова Г.П.) йөкләргә.

Әлмәт муниципаль районы Башлыгы Т.Д. Нагуманов